РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» июля 2022 ел г. Альметьевск № 1547

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертергә:

- «Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә хәзинә эзләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 6 февралендәге 189 номерлы (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 26 ноябрендәге 2063 номерлы, 2020 елның 16 июлендәге 957 номерлы, 2020 елның 30 декабрендәге 1981 номерлы, 2021 елның 2 ноябрендәге 1567 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
- «Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 912 номерлы;
- «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне яисә җир кишәрлеген файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 913 номерлы (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 1 декабрендәге 1712 номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 311 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);
- «Җир яисә җир кишәрлекләрен билгеле бер категориягә кертү яисә җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 914 номерлы;
- «Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) муниципаль милектәге

җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 915 номерлы;

- «Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 916 номерлы;

- «Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 19 ноябрендәге 1641 номерлы;

- «Милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү, муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1667 номерлы;

- «Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 24 декабрендәге 1914 номерлы;

- «Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 24 декабрендәге 1915 номерлы:

1 нче кушымтаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итеп, 3.0 пункты белән тулыландырырга:

«3.0. Күрсәтелгән хезмәт күрсәтүне гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар алган муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары.

3.0.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең гомуми билгеләре белән берләшкән категориясенә бәйле түгел. Шуңа бәйле рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми билгеләре белән берләштерелгән гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, билгеләнми».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник»газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов

